**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
04.09.2019

КАРАР
ПР-181

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 нче елның 14 нче августында кабул ителгән ПР-512 нче номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Актаныш муниципаль районы вәкаләтләрен тормышка ашыру максатыннан чыгып, Актаныш муниципаль районы составына керүче җирлекләрдә яшәүчеләрне җәмәгать туклануы, сәүдә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы максатында,

**карар бирәм:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 14 августындагы ПР-512 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 пунктындагы 4.14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «4.14. наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз куллануын иртә ачыклау максатыннан, укучыларга социаль-психологик тест оештыру. Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрүне оештыру тәртибе гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. Югары белем бирү оешмаларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрүне оештыру тәртибе югары белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә;»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л. Ф.Нурлыева